Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

№ 14 «15»июнь 2015ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 елдагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләүче затка пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибен, 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә. Газизов.